СОВЕТ КОРГУЗИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ КАРАГУЖА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ | КАРАР

17.10.2022 | с. Коргуза | 25-129

# Югары Ослан муниципаль районы Карагуҗа авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларның, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативларына үзгәрешләр кертү турында

«Татарстан Республикасында үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы муниципаль берәмлекләр башлыкларын, муниципаль берәмлекләр башлыклары урынбасарларын, депутатларны, җирле үзидарәнең сайланулы органнары әгъзаларын, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләрен һәм муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфа окладларын айлык акчалата бүләкләү күләмнәрен арттыру турында» 2022 елның 22 августындагы 881 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә, Югары Ослан муниципаль районы Карагуҗа авыл җирлеге Уставы белән,

Татарстан Республикасы
Югары Ослан муниципаль районы
Карагуҗа авыл җирлеге Советы
карар итте:

1. Карагуҗа авыл җирлеге Советының 2018 елның 23 апрелендәге 41-175 номерлы карары белән расланган Югары Ослан муниципаль районы Карагуҗа авыл җирлегенең җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәткәрләре өчен үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының хезмәте өчен түләүгә чыгымнар формалаштыру нормативларына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә (2020 елның 28.10.2020 ел № 02-16 үзгәшрешләр белән):

1.1. Карарга 1нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Югары Ослан муниципаль районы
Карагуҗа авыл җирлеге Советының
2022 елның «17» октябреннән
№ 25-129 карарына
1 кушымта

Югары Ослан муниципаль районы Карагуҗа авыл җирлеге җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладлары күләме

| Вазифа атамасы | Вазыйфаи оклад күләме (сумнарда) |
|---|---|
| Башкарма комитет сәркатибе | 15904 |

1.2. Карарга 12нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Югары Ослан муниципаль районы
Карагуҗа авыл җирлеге Советының
2022 елның «17» октябреннән
№ 25-129 карарына
12 нче кушымта

Югары Ослан муниципаль районы Карагуҗа авыл җирлеге башлыгының акчалата бүләкләре күләме

| Вазифа атамасы | Акчалата бүләкләү күләме (сумнарда) |
|---|---|
| Җирлек башлыгы | 16389 |

2. Әлеге карар 2022 елның 1 октябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Югары Ослан муниципаль районының Карагуҗа авыл җирлеге Советының социаль-мәдәни, законлылык һәм хокук тәртибе буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Совет Рәисе
Югары Ослан муниципаль районы
Карагуҗа авыл җирлеге башлыгы Д.В.Плохов